| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>Табарлинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Тәбәрле авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

30.11.2021 Тәбәрле авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мукшур торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге башлыгы к а р а р итте:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мукшур торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 10 декабренә 09 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: « 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мукшур торак пункты территориясендә, I группа инвал идлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертүгә һәм

алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә чабу эшләре башкару өчен чапкыч сатып алу;
- Мукшур авылында урам утларына хезмәт күрсәтү һәм электрик хезмәтенә договор буенча түләү;
- Мукшур авылындагы юлларга хезмәт күрсәтү - кардан чистарту;
- Мукшур авылы территориясен төзекләндерү буенча чаралар ( хуҗасыз участоклар территорияләрен җыештыру, коймаларны алыштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Мукшур ав., Ленин ур. 32Б адресы кибет каршындагы территориядә уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru) Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында(http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.САЛИМУЛЛИН